# ЗАКОН
## РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в отдельные законодательные акты Республики Татарстан**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
23 сентября 2021 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 7 июня 2004 года № 37-ЗРТ «О Счетной палате Республики Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 10 октября 2011 года № 65-ЗРТ) (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 6; 2011, № 10 (I часть); 2013, № 3; 2014, № 6 (I часть); 2016, № 4; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 55 (часть I); 2018, № 83 (часть I); 2019, № 19 (часть I), № 49 (часть I); 2021, № 1 (часть I), № 57 (часть I) следующие изменения:

1) в статье 1:
а) часть 2 после слов «муниципальных образований» дополнить словами «(далее – Федеральный закон)»;
б) дополнить частью 7 следующего содержания:
«7. Счетная палата может учреждать ведомственные награды и знаки отличия, утверждать положения об этих наградах и знаках, их описания и рисунки, порядок награждения.»;

2) статью 3 после слова «независимости» дополнить словом «, открытости»;

3) в части 4 статьи 4 слова «по предложению Председателя Счетной палаты в количестве, позволяющем обеспечить осуществление возложенных на нее полномочий, а также полномочий по внешнему муниципальному финансовому контролю, переданных на основании соглашений, заключенных с представительными органами муниципальных образований Республики Татарстан в порядке, установленном статьей $32^{1}$ настоящего Закона» заменить словами «по представлению Председателя Счетной палаты с учетом необходимости

выполнения возложенных законодательством полномочий, обеспечения организационной и функциональной независимости Счетной палаты»;

4) в статье 5:

а) в части 3 слова «за один месяц» заменить словами «за два месяца»;

б) дополнить частью $4^1$ следующего содержания:

«$4^1$. Государственный Совет Республики Татарстан обращается в Счетную палату Российской Федерации за заключением о соответствии кандидатур на должность Председателя Счетной палаты квалификационным требованиям, установленным Федеральным законом.»;

5) часть 1 статьи 8 изложить в следующей редакции:

«1. На должность Председателя, заместителя Председателя и аудиторов Счетной палаты назначаются граждане Российской Федерации, соответствующие следующим квалификационным требованиям:

1) наличие высшего образования;

2) опыт работы в области государственного, муниципального управления, государственного, муниципального контроля (аудита), экономики, финансов, юриспруденции не менее пяти лет;

3) знание Конституции Российской Федерации, федерального законодательства, в том числе бюджетного законодательства Российской Федерации и иных нормативных правовых актов, регулирующих бюджетные правоотношения, законодательства Российской Федерации о противодействии коррупции, Конституции Республики Татарстан, законов Республики Татарстан и иных нормативных правовых актов применительно к исполнению должностных обязанностей, а также общих требований к стандартам внешнего государственного и муниципального аудита (контроля) для проведения контрольных и экспертно-аналитических мероприятий контрольно-счетными органами субъектов Российской Федерации и муниципальных образований, утвержденных Счетной палатой Российской Федерации.»;

6) в пункте 3 части 1 статьи 10 слова «от 7 февраля 2011 года № 6-ФЗ «Об общих принципах организации и деятельности контрольно-счетных органов субъектов Российской Федерации» исключить;

7) статью 12 дополнить частью $1^1$ следующего содержания:

«$1^1$. В целях настоящего Закона к инспекторам Счетной палаты относятся государственные гражданские служащие Республики Татарстан, замещающие в аппарате Счетной палаты должности главного инспектора, ведущего инспектора, а также должности начальника управления с двойным наименованием, начальника отдела с двойным наименованием в соответствии с Реестром должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан.»;

8) статью 13 изложить в следующей редакции:

«Статья 13. **Полномочия Счетной палаты**

1. Счетная палата осуществляет следующие полномочия:

1) организация и осуществление контроля за законностью и эффективностью использования средств бюджета Республики Татарстан, бюджетов территориальных государственных внебюджетных фондов Республики Татарстан, а также иных средств в случаях, предусмотренных законодательством Российской Федерации;

2) экспертиза проекта закона о бюджете Республики Татарстан, проектов законов о бюджетах территориальных государственных внебюджетных фондов Республики Татарстан, проектов законов о внесении изменений в закон о бюджете Республики Татарстан и в законы о бюджетах территориальных государственных внебюджетных фондов Республики Татарстан, проверка и анализ обоснованности их показателей;

3) внешняя проверка годового отчета об исполнении бюджета Республики Татарстан, об исполнении местного бюджета в пределах компетенции, установленной Бюджетным кодексом Российской Федерации, годового отчета об исполнении бюджетов территориальных государственных внебюджетных фондов Республики Татарстан;

4) проведение аудита в сфере закупок товаров, работ и услуг в соответствии с Федеральным законом от 5 апреля 2013 года № 44-ФЗ «О контрактной системе в сфере закупок товаров, работ, услуг для обеспечения государственных и муниципальных нужд»;

5) оценка эффективности формирования государственной собственности Республики Татарстан, управления и распоряжения такой собственностью и контроль за соблюдением установленного порядка формирования такой собственности, управления и распоряжения такой собственностью (включая исключительные права на результаты интеллектуальной деятельности);

6) оценка эффективности предоставления налоговых и иных льгот и преимуществ, бюджетных кредитов за счет средств бюджета Республики Татарстан, а также оценка законности предоставления государственных гарантий и поручительств или обеспечения исполнения обязательств другими способами по сделкам, совершаемым юридическими лицами и индивидуальными предпринимателями за счет средств бюджета Республики Татарстан и имущества, находящегося в государственной собственности Республики Татарстан;

7) экспертиза проектов законов и иных нормативных правовых актов органов государственной власти Республики Татарстан в части, касающейся расходных обязательств Республики Татарстан, экспертиза проектов законов Республики Татарстан, приводящих к изменению доходов бюджета Республики Татарстан и бюджетов территориальных государственных внебюджетных фондов Республики Татарстан, а также государственных программ Республики Татарстан (проектов государственных программ Республики Татарстан);

8) анализ и мониторинг бюджетного процесса в Республике Татарстан, в том числе подготовка предложений по устранению выявленных отклонений в

бюджетном процессе и совершенствованию бюджетного законодательства Российской Федерации;

9) контроль за законностью и эффективностью использования межбюджетных трансфертов, предоставленных из бюджета Республики Татарстан бюджетам муниципальных образований, расположенных на территории Республики Татарстан, а также проверка местного бюджета в случаях, установленных Бюджетным кодексом Российской Федерации;

10) проведение оперативного анализа исполнения и контроля за организацией исполнения бюджета Республики Татарстан, бюджетов территориальных государственных внебюджетных фондов Республики Татарстан в текущем финансовом году, ежеквартальное представление информации о ходе исполнения бюджета Республики Татарстан, бюджетов территориальных государственных внебюджетных фондов Республики Татарстан, о результатах проведенных контрольных и экспертно-аналитических мероприятий Президенту Республики Татарстан, в Государственный Совет Республики Татарстан;

11) осуществление контроля за состоянием государственного внутреннего и внешнего долга Республики Татарстан;

12) оценка реализуемости, рисков и результатов достижения целей социально-экономического развития Республики Татарстан, предусмотренных документами стратегического планирования Республики Татарстан, в пределах компетенции Счетной палаты;

13) участие в пределах полномочий в мероприятиях, направленных на противодействие коррупции;

14) иные полномочия в сфере внешнего государственного финансового контроля, установленные федеральными законами, Конституцией Республики Татарстан и законами Республики Татарстан.

2. Счетная палата осуществляет полномочия по внешнему муниципальному финансовому контролю в случае заключения с представительными органами муниципальных образований Республики Татарстан соглашений о передаче указанных полномочий в порядке, установленном статьей $32^1$ настоящего Закона.

3. Счетная палата в целях обеспечения реализации части 11 статьи 6 Федерального закона устанавливает порядок проведения проверки соответствия кандидатур на должность председателя контрольно-счетного органа муниципального образования квалификационным требованиям, указанным в части 2 статьи 7 Федерального закона.

4. Внешний государственный финансовый контроль осуществляется Счетной палатой:

1) в отношении органов государственной власти и государственных органов Республики Татарстан, органов территориальных государственных внебюджетных фондов Республики Татарстан, государственных учреждений и унитарных предприятий Республики Татарстан, а также иных организаций, если они используют имущество, находящееся в государственной собственности Республики Татарстан;

2) в отношении органов местного самоуправления и муниципальных органов в Республике Татарстан и иных лиц в случаях, предусмотренных Бюджетным кодексом Российской Федерации и другими федеральными законами.»;

9) в статье 15:

а) в наименовании слова «и муниципального» исключить;

б) часть 1 изложить в следующей редакции:

«1. Стандарты внешнего государственного финансового контроля для проведения контрольных и экспертно-аналитических мероприятий утверждаются Счетной палатой в соответствии с общими требованиями, утвержденными Счетной палатой Российской Федерации.»;

в) часть 3 признать утратившей силу;

10) в статье 16:

а) в части 2 слова «и запросов» исключить;

б) часть 3 изложить в следующей редакции:

«3. Предложения Президента Республики Татарстан, поручения Государственного Совета Республики Татарстан включаются в годовой план деятельности Счетной палаты по решению Коллегии Счетной палаты в 10-дневный срок со дня их поступления.»;

11) статью 19 дополнить частью $2^1$ следующего содержания:

«$2^1$. Руководители проверяемых органов и организаций обязаны обеспечивать соответствующих должностных лиц Счетной палаты, участвующих в контрольных мероприятиях, оборудованным рабочим местом с доступом к справочным правовым системам, информационно-телекоммуникационной сети Интернет.»;

12) в статье 20:

а) часть 1 после слов «финансовый контроль» дополнить словами «или которые обладают информацией, необходимой для осуществления внешнего государственного финансового контроля»;

б) в части 2 слова «и запросов» исключить;

в) дополнить частью 10 следующего содержания:

«10. При осуществлении внешнего государственного финансового контроля Счетной палате предоставляется необходимый для реализации ее полномочий постоянный доступ к государственным и муниципальным информационным системам в соответствии с законодательством Российской Федерации об информации, информационных технологиях и о защите информации, законодательством Российской Федерации о государственной и иной охраняемой законом тайне.»;

13) в статье 21:

а) наименование изложить в следующей редакции:

**«Оперативный анализ исполнения и контроль за организацией исполнения бюджета Республики Татарстан и бюджетов территориальных государственных внебюджетных фондов Республики Татарстан»**;

б) часть 1 изложить в следующей редакции:

«1. Счетная палата в процессе исполнения бюджета Республики Татарстан, бюджетов территориальных государственных внебюджетных фондов Республики Татарстан анализирует полноту и своевременность поступлений доходов, исполнение расходов бюджетов и источников финансирования дефицитов бюджетов в сравнении с утвержденными показателями закона о бюджете Республики Татарстан, законов о бюджетах территориальных государственных внебюджетных фондов Республики Татарстан, выявляет отклонения и нарушения, проводит их анализ, вносит предложения по их устранению.»;

в) часть 3 изложить в следующей редакции:

«3. Данные оперативного анализа исполнения бюджета Республики Татарстан и бюджетов территориальных государственных внебюджетных фондов Республики Татарстан и контроля за организацией их исполнения в текущем финансовом году используются при планировании контрольных и экспертно-аналитических мероприятий.»;

14) в статье 25:

а) в части 1 слова «их рассмотрения и» исключить, после слова «выявленных» дополнить словами «бюджетных и иных»;

б) в части 3 слова «в течение одного месяца со дня получения представления» заменить словами «в указанный в представлении срок или, если срок не указан, в течение 30 дней со дня его получения», слово «рассмотрения» заменить словом «выполнения»;

в) дополнить частью $3^1$ следующего содержания:

«$3^1$. Срок выполнения представления может быть продлен по решению Счетной палаты, но не более одного раза.»;

г) часть 4 после слов «их пресечению и предупреждению,» дополнить словами «невыполнения представлений Счетной палаты,»;

д) часть 6 дополнить предложением следующего содержания: «Срок выполнения предписания может быть продлен по решению Счетной палаты, но не более одного раза.»;

е) часть 7 изложить в следующей редакции:

«7. Невыполнение представления или предписания Счетной палаты влечет за собой ответственность, установленную законодательством Российской Федерации.»;

15) в части 1 статьи 26:

а) пункт 1 дополнить словами «, а также проекты законов о внесении изменений в закон о бюджете Республики Татарстан и в законы о бюджетах

территориальных государственных внебюджетных фондов Республики Татарстан»;

б) пункты 3 и 4 изложить в следующей редакции:

«3) проекты законов и иных нормативных правовых актов органов государственной власти Республики Татарстан в части, касающейся расходных обязательств Республики Татарстан, проекты законов Республики Татарстан, приводящих к изменению доходов бюджета Республики Татарстан и бюджетов территориальных государственных внебюджетных фондов Республики Татарстан;

4) государственные программы Республики Татарстан (проекты государственных программ Республики Татарстан);»;

16) в статье 31:

а) часть 6 изложить в следующей редакции:

«6. Должностным лицам Счетной палаты гарантируются ежегодные оплачиваемые отпуска (основной и дополнительные), профессиональное развитие, в том числе получение дополнительного профессионального образования, а также другие меры материального и социального обеспечения, установленные для лиц, замещающих государственные должности и должности государственной гражданской службы Республики Татарстан (в том числе по медицинскому и санаторно-курортному обеспечению, бытовому, транспортному и иным видам обслуживания).»;

б) часть 7 признать утратившей силу;

17) в статье 32:

а) дополнить частью $1^1$ следующего содержания:

«$1^1$. Счетная палата вправе на основе заключенных соглашений о сотрудничестве и взаимодействии привлекать к участию в проведении контрольных и экспертно-аналитических мероприятий контрольные, правоохранительные и иные органы и их представителей, а также на договорной основе аудиторские, научно-исследовательские, экспертные и иные учреждения и организации, отдельных специалистов, экспертов, переводчиков.»;

б) часть 6 дополнить пунктом 6 следующего содержания:

«6) по обращениям представительных органов муниципальных образований давать заключения о соответствии кандидатур на должность председателя контрольно-счетного органа муниципального образования требованиям, установленным Федеральным законом.»;

в) дополнить частью 7 следующего содержания:

«7. Государственный Совет Республики Татарстан или Счетная палата вправе обратиться в Счетную палату Российской Федерации за заключением о соответствии деятельности Счетной палаты законодательству о внешнем государственном финансовом контроле и рекомендациями по повышению ее эффективности.».

**Статья 2**

Внести в часть 2 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 12 февраля 2009 года № 15-ЗРТ «О гарантиях осуществления полномочий депутата представительного органа муниципального образования, члена выборного органа местного самоуправления, выборного должностного лица местного самоуправления в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2009, № 2; 2010, № 1 – 2; 2011, № 5; 2012, № 12 (II часть); 2014, № 6 (II часть), № 12 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2018, № 1 (часть I); 2019, № 2 (часть I); 2020, № 26 (часть I), № 87 (часть I) изменение, заменив слова «контрольно-счетного органа муниципального образования, а также на заместителя председателя и аудитора контрольно-счетного органа муниципального образования, если указанные должности в установленном порядке отнесены к муниципальным должностям» словами «, заместителя председателя и аудитора контрольно-счетного органа муниципального образования».

**Статья 3**

Внести в Закон Республики Татарстан от 17 мая 2012 года № 21-ЗРТ «Об отдельных вопросах организации и деятельности контрольно-счетных органов муниципальных образований Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстан, 2012, № 5 (I часть) следующие изменения:

1) статью 2 признать утратившей силу;

2) в статье 4:

а) в части 1 слова «Федеральным законом» заменить словами «федеральными законами»;

б) в части 2 слова «и запросов» исключить.

**Статья 4**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
04 октября 2021 года
№ 77-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» 2004 елның 7 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2011 елның 10 октябрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 6; 2011, № 10 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 6 (I өлеш); 2016, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 83 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:
а) 2 өлештә «Федераль законга» сүзләреннән соң «(алга таба – Федераль закон)» сүзләрен өстәргә;
б) түбәндәге эчтәлекле 7 өлеш өстәргә:
«7. Хисап палатасы ведомство бүләкләрен һәм мактау билгеләрен гамәлгә куя ала, бу бүләкләр һәм билгеләр турындагы нигезләмәләрне, аларның тасвирламаларын һәм рәсемнәрен, бүләкләү тәртибен раслый ала.»;

2) 3 статьяда «бәйсезлек» сүзеннән соң «, ачыклык» сүзен өстәргә;

3) 4 статьяның 4 өлешендә «аңа йөкләнгән вәкаләтләрне, шулай ук әлеге Законның $32^1$ статьясында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең вәкиллекле органнары белән төзелгән килешүләр нигезендә тапшырылган тышкы муниципаль финанс контроле вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итәрлек санда Хисап палатасы Рәисе тәкъдиме буенча» сүзләрен «, законнар белән йөкләнгән вәкаләтләрне үтәү, Хисап палатасының оештыру һәм функциональ бәйсезлеген тәэмин итү кирәклеген исәпкә алып, Хисап палатасы Рәисе тәкъдиме буенча» сүзләренә алмаштырырга;

4) 5 статьяда:

а) 3 өлештә «бер айдан да» сүзләрен «ике айдан да» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 4[1] өлеш өстәргә:

«4[1]. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Хисап палатасы Рәисе вазыйфасына кандидатураларның Федераль законда билгеләнгән квалификацион таләпләргә туры килүе турындагы бәяләмәне сорап Россия Федерациясе Хисап палатасына мөрәҗәгать итә.»;

5) 8 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Хисап палатасының Рәисе, Рәис урынбасары һәм аудиторлары вазыйфаларына түбәндәге квалификацион таләпләргә туры килә торган Россия Федерациясе гражданнары билгеләнеп куела:

1) югары белемле;

2) дәүләт идарәсе, муниципаль идарә, дәүләт тикшереп торуы, муниципаль контроль (аудит), икътисад, финанс, юриспруденция өлкәсендә кимендә биш ел эш тәҗрибәсе булган;

3) Россия Федерациясе Конституциясен, федераль законнарны, шул исәптән Россия Федерациясе бюджет законнарын һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы башка норматив хокукый актларны, коррупциягә каршы тору турындагы Россия Федерациясе законнарын, Татарстан Республикасы Конституциясен, вазыйфаи бурычларны үтәүгә кагылышлы Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларны, шулай ук Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары тарафыннан тикшереп тору чараларын һәм эксперт-аналитик чараларны үткәрү өчен тышкы дәүләт аудиты һәм муниципаль аудит (тикшереп тору) стандартларына карата Россия Федерациясе Хисап палатасы раслаган гомуми таләпләрне белгән.»;

6) 10 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктында «“Россия Федерациясе субъектларының контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында” 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы» сүзләрен төшереп калдырырга;

7) 12 статьяга түбәндәге эчтәлекле 1[1] өлеш өстәргә:

«1[1]. Әлеге Закон максатларында Хисап палатасы инспекторларына Хисап палатасы аппаратында баш инспектор, әйдәүче инспектор вазыйфаларын, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестры нигезендә идарә башлыгының, бүлек башлыгының ике исемле вазыйфаларын биләүче Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре керә.»;

8) 13 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13 статья. **Хисап палатасы вәкаләтләре**

1. Хисап палатасы түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) Татарстан Республикасы бюджеты, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетлары акчаларыннан, шулай ук Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда башка акчалардан файдалануның законлылыгын һәм нәтиҗәлелеген тикшереп торуны оештыру һәм гамәлгә ашыру;

2) Татарстан Республикасы бюджеты турындагы закон проектына, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетлары хакындагы законнар проектларына, Татарстан Республикасы бюджеты турындагы законга һәм Татарстан Республикасы бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетлары хакындагы законнарга үзгәрешләр кертү турындагы законнар проектларына экспертиза ясау, аларның күрсәткечләренең нигезле булуын тикшерү һәм анализлау;

3) Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше, җирле бюджет үтәлеше турындагы еллык хисапны, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетлары үтәлеше хакындагы еллык хисапны тышкы тикшерү;

4) «Дәүләт ихтыяҗлары һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә товарларны, эшләрне һәм хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә аудит үткәрү;

5) Татарстан Республикасы дәүләт милкен булдыруның, мондый милек белән идарә итүнең һәм эш йөртүнең нәтиҗәлелеген бәяләү һәм шушы милекне булдыруның, мондый милек белән идарә итүнең һәм эш йөртүнең билгеләнгән тәртибен үтәүне тикшереп тору (интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә махсус хокукларны да кертеп);

6) Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән салым ташламаларын һәм башка ташламаларны һәм өстенлекләрне, бюджет кредитларын бирүнең нәтиҗәлелеген бәяләү, шулай ук дәүләт гарантияләрен һәм поручительлекләрне бирүнең яисә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары һәм Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге мөлкәт исәбеннән юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан башкарыла торган алыш-бирешләр буенча йөкләмәләрне бүтән ысуллар белән үтәүне тәэмин итүнең законлылыгын бәяләү;

7) законнар проектларына һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының башка норматив хокукый актларына Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләренә кагылышлы өлешендә экспертиза ясау, Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетлары керемнәренең үзгәрүенә китерә торган Татарстан Республикасы законнары проектларына, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт программаларына (Татарстан Республикасы дәүләт программалары проектларына) экспертиза ясау;

8) Татарстан Республикасында бюджет процессын анализлау һәм мониторинглау, шул исәптән бюджет процессында ачыкланган тайпылышларны бетерү һәм Россия Федерациясе бюджет законнарын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

9) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелгән бюджетара трансфертлардан файдалануның законлылыгын һәм нәтиҗәлелеген тикшереп тору, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән очракларда җирле бюджетны тикшерү;

10) Татарстан Республикасы бюджетының, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетларының агымдагы финанс елында үтәлешенә оператив анализ үткәрү һәм үтәлешне оештыруны тикшереп тору, квартал саен Татарстан Республикасы бюджетының, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетларының үтәлеше турында, үткәрелгән тикшереп тору чаралары һәм эксперт-аналитик чаралар нәтиҗәләре хакында Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына мәгълүмат бирү;

11) Татарстан Республикасының дәүләт эчке һәм тышкы бурычының торышын тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

12) Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларында каралган Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше максатларына ирешүнең тормышка ашу мөмкинлекләрен, куркынычларын һәм нәтиҗәләрен Хисап палатасы компетенциясе чикләрендә бәяләү;

13) коррупциягә каршы торуга юнәлдерелгән чараларда вәкаләтләре чикләрендә катнашу;

14) тышкы дәүләт финанс контроле өлкәсендә федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән башка вәкаләтләр.

2. Хисап палатасы, әлеге Законның $32^1$ статьясында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең вәкиллекле органнары белән тышкы муниципаль финанс контроле вәкаләтләрен тапшыру турында килешүләр төзелгән очракта, күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

3. Хисап палатасы Федераль законның 6 статьясындагы 11 өлешен гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе вазыйфасына кандидатураларның Федераль законның 7 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән квалификацион таләпләргә туры килүен тикшерүне үткәрү тәртибен билгели.

4. Тышкы дәүләт финанс контроле Хисап палатасы тарафыннан түбәндәгеләргә карата гамәлгә ашырыла:

1) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм дәүләт органнарына, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә һәм унитар предприятиеләренә, шулай ук башка оешмаларга карата, әгәр алар Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге мөлкәттән файдалансалар;

2) җирле үзидарә органнарына һәм Татарстан Республикасында муниципаль органнарга һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм башка федераль законнарда каралган очракларда бүтән затларга карата.»;

9) 15 статьяда:

а) исемендә «һәм муниципаль» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Тикшереп тору чараларын һәм эксперт-аналитик чараларны үткәрү өчен тышкы дәүләт финанс контроле стандартлары Хисап палатасы тарафыннан Россия Федерациясе Хисап палатасы раслаган гомуми таләпләр нигезендә раслана.»;

в) 3 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

10) 16 статьяда:

а) 2 өлештә «һәм гарызнамәләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимнәре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы йөкләмәләре Хисап палатасы Коллегиясе карары белән аларның кергән көненнән алып 10 көнлек срокта Хисап палатасы эшчәнлегенең еллык планына кертелә.»;

11) 19 статьяга түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

«$2^1$. Тикшерелә торган органнарның һәм оешмаларның җитәкчеләре тикшереп тору чараларында катнашучы Хисап палатасының тиешле вазыйфаи затларын белешмә хокук системаларыннан, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдалана алу мөмкинлеге белән җиһазландырылган эш урыны белән тәэмин итәргә тиеш.»;

12) 20 статьяда:

а) 1 өлештә «хокуклы булган» сүзләреннән соң «яисә тышкы дәүләт финанс контролен гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматка ия булган» сүзләрен өстәргә;

б) 2 өлештә «һәм гарызнамәләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 10 өлеш өстәргә:

«10. Тышкы дәүләт финанс контроле гамәлгә ашырылганда мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүматны яклау турындагы Россия Федерациясе законнары, дәүләт сере һәм закон белән саклана торган башка сер хакындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә Хисап палатасына аның вәкаләтләрен башкару өчен кирәкле булган дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системаларыннан даими файдалана алу мөмкинлеге бирелә.»;

13) 21 статьяда:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«Татарстан Республикасы бюджетының һәм Татарстан Республикасы бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетларының үтәлешенә оператив анализ һәм аларның үтәлешен оештыруны тикшереп тору»;**

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Хисап палатасы Татарстан Республикасы бюджетын, Татарстан Республикасының бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетларын үтәү барышында керемнәрнең тулысынча һәм вакытында керүен, Татарстан

Республикасы бюджеты турындагы законның, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетлары хакындагы законнарның расланган күрсәткечләре белән чагыштырганда бюджет чыгымнары һәм кытлыкларны финанслау чыганаклары үтәлешен анализлый, тайпылышларны һәм хокук бозуларны ачыклый, аларга анализ үткәрә, аларны бетерү буенча тәкъдимнәр кертә.»;

в) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы бюджетының һәм Татарстан Республикасы бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетларының агымдагы финанс елында үтәлешен оператив анализлау һәм аларның үтәлешен оештыруны тикшереп тору белешмәләре тикшереп тору чараларын һәм эксперт-аналитик чараларны планлаштырганда файдаланыла.»;

14) 25 статьяда:

а) 1 өлештә «карау һәм» сүзләрен төшереп калдырырга, «ачыкланган» сүзеннән соң «бюджет хокук бозуларын һәм кимчелекләрен, башка» сүзләрен өстәргә;

б) 3 өлештә «тәкъдимне алган көннән бер ай эчендә» сүзләрен «тәкъдимдә күрсәтелгән срокта яисә, срогы күрсәтелмәгән булса, аны алган көннән алып 30 көн эчендә» сүзләренә, «тәкъдимне карау» сүзләрен «тәкъдимне үтәү» сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ өлеш өстәргә:

«$3^1$. Тәкъдимне үтәү срогы Хисап палатасы карары белән озайтылырга мөмкин, әмма бер тапкырдан да артыкка түгел.»;

г) 4 өлештә «хокук бозулар ачыкланган» сүзләреннән соң «, Хисап палатасы күрсәтмәләре үтәлмәгән» сүзләрен өстәргә;

д) 6 өлештә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Күрсәтмәне үтәү срогы Хисап палатасы карары белән озайтылырга мөмкин, әмма бер тапкырдан да артыкка түгел.»;

е) 7 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Хисап палатасы тәкъдимен яисә күрсәтмәсен үтәмәү Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән җаваплылыкка китерә.»;

15) 26 статьяның 1 өлешендә:

а) 1 пунктта «, шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты турындагы законга һәм Татарстан Республикасы бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетлары хакындагы законнарга үзгәрешләр кертү турындагы законнар проектларына» сүзләрен өстәргә;

б) 3 һәм 4 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) законнар проектларына һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының башка норматив хокукый актларына Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләренә кагылышлы өлешендә, Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары

бюджетлары керемнәренең үзгәрүенә китерә торган Татарстан Республикасы законнары проектларына;

4) Татарстан Республикасы дәүләт программаларына (Татарстан Республикасы дәүләт программалары проектларына);»;

16) 31 статьяда:

а) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Хисап палатасының вазыйфаи затларына ел саен түләүле отпусклар (төп һәм өстәмә), һөнәри үсеш, шул исәптән өстәмә һөнәри белем алу, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче затлар өчен билгеләнгән башка матди һәм социаль тәэминат чаралары (шул исәптән, медицина һәм шифаханә-курорт тәэминаты, көнкүреш, транспорт буенча хезмәт күрсәтү һәм хезмәт күрсәтүнең бүтән төрләре буенча) гарантияләнә.»;

б) 7 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

17) 32 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

«$1^1$. Хисап палатасы хезмәттәшлек һәм үзара эшләү турында төзелгән килешүләр нигезендә тикшереп тору чараларын һәм эксперт-аналитик чараларны үткәрүдә катнашуга тикшереп тору, хокук саклау органнарын һәм башка органнарны, аларның вәкилләрен, шулай ук шартнамә нигезендә аудитор, фәнни-тикшеренү, эксперт учреждениеләрен, оешмаларын һәм башка учреждениеләрне, оешмаларны, аерым белгечләрне, экспертларны, тәрҗемәчеләрне җәлеп итәргә хокуклы.»;

б) 6 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6) муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары мөрәҗәгатьләре буенча муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе вазыйфасына кандидатураларның Федераль законда билгеләнгән таләпләргә туры килүе турындагы бәяләмәләр бирергә.»;

в) түбәндәге эчтәлекле 7 өлеш өстәргә:

«7. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы яисә Хисап палатасы аның эшчәнлегенең тышкы дәүләт финанс контроле турындагы законнарга туры килүе хакындагы бәяләмәне һәм Хисап палатасы эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру буенча тәкъдимнәрне сорап Россия Федерациясе Хисап палатасына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 2;

2010, № 1 – 2; 2011, № 5; 2012, № 12 (II өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш), «муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисенә дә, шулай ук муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе урынбасарына һәм аудиторына, әгәр күрсәтелгән вазыйфалар билгеләнгән тәртиптә муниципаль вазыйфаларга кертелгән булса,» сүзләрен «шулай ук муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисенә, рәисе урынбасарына һәм аудиторына да» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең аерым мәсьәләләре турында» 2012 елның 17 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 5 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 4 статьяда:

а) 1 өлештә «Федераль закон» сүзләрен «федераль законнар» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «һәм гарызнамәләре» сүзләрен төшереп калдырырга.

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 04 октябрь
№ 77-ТРЗ